ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево, 422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БОРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы, 422579

Тел.: (84379) 36-2-45, факс: (84379) 36-2-45.

2024 елның 30 ноябре №1

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме? " - Татар Борнашы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән сорау буенча 2024 елның 30 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы ______449___ кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан җыенында катнашучылар саны ________227___ кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен - гражданнар җыенында катнашучы 225 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авылы җирлегенең Татар Борнашы авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип таныырга.

2. Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче С. В. Бурукин